## 27нче гыйнвар – Россиядә хәрби дан көне – Ленинградны фашистлар блокадасыннан тулысынча азат итү көне

27нче гыйнвар – Россиядә хәрби дан көне - Ленинградны фашистлар блокадасыннан тулысынча азат итү көне. Бүген район үзәгендәге «Батырлар аллеясы» паркында митинг узды. Үзәктә урнашкан оешма-предприятие, район Советы һәм башкарма комитетның бүлек хезмәткәрләре, «Форпост» вәкилләре, «Яшьармиячеләр», волонтерлар, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, мәктәп укучылары һәм укытучылар катнашында Балтач җирлегенең батыр улларын – райондашларыбызны бер минут тынлык белән искә алдылар.

